ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» Татарстан Республикасы Законының 26 һәм 27 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш); 2008, № 1, № 12 (VI өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 4; 2015, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 26 статьяда:
а) 3 пунктта «карый» сүзеннән соң «, шулай ук утырышлар чакырмыйча гына карарлар кабул итә» сүзләрен өстәргә;
б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларын әзерләү һәм уздыру, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан карарлар әзерләү һәм аларны утырышлар чакырмыйча гына кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2) 27 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27 статья. **Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында карала торган мәсьәләләр**

1. Түбәндәге мәсьәләләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында гына каралалар:
Татарстан Республикасы бюджеты проекты турында һәм аның үтәлеше хакындагы хисап турында;

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты проекты турында һәм аның үтәлеше хакындагы хисап турында;

Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль үсеше программалары проектлары турында;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы составы хакында;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты турында;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты хакындагы нигезләмәне раслау турында.

2. Башка мәсьәләләр Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Президентының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән очракларда, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты яисә Татарстан Республикасы Премьер-министры карары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламенты белән билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышларында каралырга мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 12 декабре
№ 98-ТРЗ